СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

20 июнь, 1997ел.
ЖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 66 (8078) | Бәясе билгеләнгәнчә

## «Уңыш - 97» пресс - үзәге хәбәр итә

Соңгы вакытта ешайган яңгырлар авыл хуҗалыгындагы эшләрне үткәрүдә тоткарлык тудырмый калмады. Шулай да район хуҗалыкларының байтагы аяз көннең һәр минутын рациональ файдаланырга омтылалар. Район авыл хуҗалыгы идарәсеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, 18 нче июньгә район буенча күпьеллык үләннәрнең 2.404 гектары теземнәргә салынды. Бу - барлык мәйданның 26 проценты кадәр. «Заветы Ильича», «Кондырча» һәм «Агрохимсервис» АҖнең «Сөлчә» ярдәмче хуҗалыгы бу эшне зур оешканлык белән дәвам итәләр. Ә менә «Игенче», «Правда», «Таң» хуҗалыкларында эш темпы түбән. Соңгысында күпьеллык үләннәрнең нибары 10 гектары гына теземнәрдә әле.

Район буенча печән запасы 946 тонна тәшкил итә. Шушы көнгә гамәлдәге 28 витаминлы үлән оны ясау агрегатының нибары 13се генә эшкә җибәрелде әле. Барлыгы 78 тонна үлән оны хәзерләнде. Шуның 20 тоннасы «Кондырча»да, 14е «Заветы Ильича»да. Синдряковлылар да бу эшкә җитди якын киләләр.

Шикәр чөгендере плантацияләренең рәт араларын беренче тапкыр эшкәртү эше дә азакка якынлашып килә. Синдряков, Хафизов исемнәрендәге, «Правда» ассоциацияләре бу эшне районда беренчеләрдән булып төгәлләделәр. Ә менә МСОның «Төзүче» һәм шикәр заводының «Восход» ярдәмче хуҗалыклары акрын кыймылдыйлар әле.

Шикәр чөгендерен сирәкләү эше дәвам итә. Синдряков исемендәге, «Заветы Ильича» хуҗалыклары бу эшне тулысынча төгәлләделәр, «Родина», «Правда», Мичурин исемендәге ассоциацияләрдә дә ул азагына якынлашып килә.

6.912 гектар. 18 нче июньгә кукурузның рәт араларын эшкәртү шул кадәр мәйданда башкарылды. Бу - барлык мәйданнарның 72 проценты кадәр.

Зоя - Вишневая Поляна авылы кызы. Бөтен гомере авыл тормышы белән бәйле аның. Баштарак җиде еллап сыер савучы булды ул. Намуслы эшләде кыз. Үз карамагындагы малларыннан мөмкин кадәр күбрәк продукция җитештерү өчен ал - ял белән исәпләшмәде. Шуңа да фермага лаборант кирәк булгач, җитәкчеләр иң беренче булып аның исеменә тукталдылар.

Зоя Алексеевнаның лаборант булып эшли башлавына шактый инде. Бу һөнәрне бөтен нечкәлекләренә кадәр үзләштерү өчен бар көчен куйды ул. Хәзер Зоя Пахмулова райондагы иң тәҗрибәле лаборантлардан санала: сөткә анализны тиз дә, сыйфатлы да үткәрә ул.



Рәсемдә: Мичурин исемендәге КФХА лаборанты З.Пахмулова.
Н.АЗИЗОВ фотосы.

## Матди кызыксындыргач

**«Родина» КФХАнда быел 350 баш ана сарыктан 560 бәрән алынды.**

Бу - тулаем район буенча иң яхшы күрсәткечләрнең берсе. Яшь үрчемнең сакланышы да тәэмин ителә.

Быел хуҗалыкта сарыкларның өстен алу да әллә ни зур проблема тудырмады. Йон кырку машиналарының сафтан чыгуы сәбәпле, барлык малларның өстен кулдан алырга туры килде. Бу эш өч көндә үткәрелде дә. Ничек дисезме? Хуҗалык бу эш белән шөгыльләнүчеләрне матди кызыксындырды: килешүдә каралган сумма авыл халкына шул көндә үк бирелде.

«Кышкы күлмәкләрен» салган сарыклар хәзер лагерьда асрала. Аларны көтү дә оештырылган.

## ҮЗЕБЕЗНЕ КҮРСӘТЕРГӘ, БАШКАЛАРНЫ КАРАРГА

Мичурин исемендәге ККА 25 нче июньдә планлаштырылган сабанчылар конкурсын үткәрү базасы итеп сайланды. Үз осталыгын, техниканы белүен, аны төзәтү - көйләү сәләтен күрсәтә алган иң уңган сабанчы бүләккә «Урал» мотоциклы алачак. Икенче, өченче урыннар өчен дә призлар билгеләнде - алар бишекле «Иж - Планета» мотоциклы һәм чит илдә эшләнгән ике камералы суыткыч. Ә берничә көнгә иртәрәк Киекле КА сында икенче традицион конкурс - машина белән саву осталары ярышы уздырылачак. Терлекчеләргә биредә теоретик әзерлеге дәрәҗәсен күрсәтергә, саву аппаратларын сүтү һәм җыюда норматив вакытка сыешырга, машина белән савуда осталыгын дәлилләргә туры киләчәк. Җиңүчеләрне шулай ук кыйммәтле бүләкләр көтә. Район конкурсларына кадәр бу ярышлар барлык хуҗалыкларда узарга тиеш. Район конкурсында катнашучыларны һәммәсен акчалата премияләр көтә, ә чемпионнар исә республика ярышларында көч сынашачаклар.

## БАРЫСЫ ДА АНЫҢ ТУРЫНДА

Заманында механизатор Аркадий Кузьминга столярлык, балта остасы киләчәге юраганнар иде. Ни дисәң дә, әтисе Леонтий Петрович бу эштә бөтен авылга танылган зур оста иде бит. Әмма башкача килеп чыкты: Аркадий бөтен гомеренә механизаторлык һөнәрен сайлады. 1975 нче елның язында ул чылбырлы трактор рычагы артына, ә урып - җыю башлангач СК - 5 комбайнына утырды. Шулай 22 ел гомер үтте. Хезмәте өчен байтак бүләкләр алды. Әмма башка өлкәләрдә дә сәләтен күрсәтә торды. Мәсәлән, Мичурин исемендәге ККАның фольклор коллективында аңа йомшак тавышы өчен Леонид Утесов дип исем бирделәр, ә волейболда осталыгы өчен Юрий Чеснаков дип атадылар. Шулар өстенә ул футбол уйнады, велоспорт белән шөгыльләнде, чаңгыда йөрде, ә узган ел Аркадий үзенең «ДОН»ында 10528 центнер ашлык суктырды.

- Алдынгы комбайнчылар исәбендә булыйм дисәң бу гына аз,- ди комбайнчы.

- Ә быелга планнар нинди?

- Корыч атым бүген үк яуга чыгарга әзер, үземнең дә кәефем әйбәт. Аксумла авылыннан дустым һәм ярышташым Александр Донсковтан калышмаска исәбем.

Тиздән урак. Уңыш һәм куәт сиңа, игенче!

### Акционерлар игътибарына!

**«Норлат - Октябрь АТПсы» АҖ акционерларының гомуми җыелышы 1997 нче елның 25 нче июнендә АТПның кызыл почмагында түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Норлат шәһәре, Школьная ур., 31. Җыелыш 10 сәгатьтә башлана, акционерларны теркәү 9 сәгатьтә. Көн тәртибе:**

**1. Санау комиссиясен сайлау.**

**2. Җәмгыятьнең еллык отчетын, бухгалтерлык балансын, табыш һәм зыян счетларын, ревизия комиссиясе һәм аудитор нәтиҗәләрен раслау.**

**3. Генераль директор сайлау.**

**4. Директорлар советын сайлау.**

**5. Ревизия комиссиясен сайлау.**

**6. Аудитор турында мәсьәлә.**

**Теркәү вакытында паспорт булу шарт. Башка акционерларга ышаныч кәгазе биреп вәкаләтегезне йөкли аласыз.**

«Норлат - Октябрь АТПсы» директорлар советы.

## Үсмерләрдән бригада

Район хакиме каршындагы балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия тәэсире нәтиҗәсендә шәһәрдә төзелеш оешмаларында эшләү өчен үсмерләрдән 2 бригада оештырылды. Беренче бригадага - 10, икенчесенә - 12 үсмер язылды. Бу «авыр» балалар - күбрәк мохтаҗ гаиләләрдән, биредә тыйнак гаилә бюджетына һәр эшләп алган сум бик тансык булачак. Үсмерләр район хезмәт һәм мәшгульлек бюросы катнашында төзелгән өч яклы килешү нигезендә РСУ һәм 53 нче СМУ чикле җаваплылыктагы җәмгыятьтә эшләячәкләр. Соңгысы һәр айда үсмерләргә 167 меңәр сум акча түләүне өстенә ала. Минималь хезмәт күләменә җиткерү өчен калган сумманы, үсмерләр тырышып эшләгәндә, предприятиеләр түләячәк. Эшкә килгәндә, алар производство биналарын ремонтлауда, промбазалар территорияләрен тәртипкә салуда катнашачаклар.

## Кайда, нәрсә, ничек?




**РОССИЯДӘН ЕЛ САЕН** законсыз рәвештә 12 - 15 миллиард доллар читкә чыгарыла. Бу турыда Россия банкы рәисе беренче урынбасары Александр Хандруев әйтте.

Аның сүзләренә караганда, хәзер капиталның ялган импорт килешүләре аша чыгып ычкынуын булдырмау бик актуаль. Үзәк банкның валюта эшен җайга салу һәм валюта контроле департаменты директоры Владимир Смирновның Финанс мәгълүматлары агентлыгына биргән интервьюсыннан күренгәнчә, экспортка контроль ясауны җайга салу аркасында 1996 елда экспорттан кергән акчаның 6 - 7 проценты гына Россиягә тиешле вакытта кайтып җитмәгән, 1993 елда мондый акчаның 23 - 30 проценты гына илгә кайткан.

**ИЛНЕҢ ТӨП һАВА ПОРТЫ** «Шереметьево» Мәскәү милке булып әверелә. Башкала моның өчен Россия хөкүмәтенә шәһәрнең 300 миллиард сумлык күчемсез милкен бирә. Шәһәр хакимияте аэропортны капиталь яңартуга 200 миллион чамасы доллар сарыф итәргә җыена.

**РФ ВИЦЕ-ПРЕМЬЕРЫ АНАТОЛИЙ ЧУБАЙС** Салым дәүләт инспекциясенә һәм хөкүмәт аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына үз гаиләсенең керемнәре, милке турында декларация белән белешмә тапшырды. 1996 елда аның керемнәре 1714729623 сум тәшкил иткән. Шуның 39647211 сумы - беренче вице - премьер һәм РВ Президенты администрациясе башлыгы булып эшләгәндә алган эш хакы. 1675082412 сумы - лекция, консультация өчен гонорар, «Хосусый милекне яклау үзәге»ндә кыйммәтле кәгазьләр белән гамәлият кылудан алынган керем. Мәскәүдә 82 кв. метрлы ике бүлмәле хосусыйлаштырылган квартирасы, Мәскәү янында йорт салу өчен 19 сотый җир бүлемтеге, «Судзуки» машинасы бар икән.

**ДНЕПРОПЕТРОВСК ШӘҺӘРЕНДӘ** зур бәхетсезлек булды. «Тополь - 1» торак массивында яшәүчеләр котокычшау - шудан уянып киттәләр. Җир тетрәгән сыман тоелды. Котлары алынган кешеләр өсләренә ни кигән булсалар, урамга шулай йөгереп чыктылар, 72 квартиралы, 9 катлы йорт җир астына чума башлады, 3 сәгатьтән җир астына кереп бетте. Гадәттән тыш хәл булган урында 30 метр тирәнлектә чокыр барлыкка килде. Анда су котырынды. Шул тирәдәге ике балалар бакчасы һәм мәктәпнедә җир упты.

## «Сәламәтлек» почмагы

# Үз - үзенә ярдәм ит



***Район үзәк шифаханәсенең наркология бүлегендә клиник формалашкан чир белән 1000ләп кеше исәптә тора. Аларның яше 25тән 45кә кадәр. Шуларның 20 проценты хатын - кызлар.***

Районда наркологик хезмәт 1980 елдан башлана. Тагын 5 елдан соң алкогольгә каршы кампания башлангач бу хезмәткә игътибар тагын да арта. Табибларны ГИДУВка курсларга җибәрәләр, махсус бүлекләр ачыла, бу мәсьәлә бюджетта да чагылыш таба. 1990 елның гыйнвареннан Октябрь районы үзәк шифаханәсендә дә шундый бүлек ачыла. Анда берьюлы 25 кеше дәвалана ала. Биредә 14 кеше эшли.

- Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең 90 проценты алкоголь интоксинация һәм махмыр синдромы хәлендә киләләр. Тик кешене шул хәленнән чыгару бу әле алдагы эшнең 30 - 40 проценты гына дигән сүз, дип саный табиб - нарколог - психиатр Семен Ильич Федотов. - Дәвалау процессы 3 - 4 атна дәвам итә: беренчесендә без пациентны аякка бастырабыз, икенчесендә - алкогольгә карата сиземлелеген арттырабыз, өченчесендә психотерапевтик тәэсир итүне кулланабыз.

Икенче төрле әйткәндә, гипноз. Гипнотарий (хәер, болай әйтү бик зур) шифаханәнең өченче катында кечкенә бүлмәдә урнашкан. Заман үлчәмнәре белән чагыштырганда, бик тыйнак җиһазландырылган. Мәсәлән, тавыш изоляциясен көчәйтү комачауламас иде. Аппаратурадан тынычландыручы яки тонусны күтәрүче төрле музыкаль сюжетлар язмалары белән магнитофон гына бар. Беренче чиратта, әлбәттә, видеокамера, телевизор кирәк, әшәке чагыңны төшереп күрсәтсәң, бәлки, айнып та китәр идең... Менә терапия.

ТР Минстрлар Кабинетының 711 нче карары буенча 2000 нче елга кадәр башкалары белән бергә бу максатларга 61 миллион акча бүленә. Коллегалары кебек үк С.И.Федотов та бу ярдәмгә зур өмет баглый.

Ул үткәрә торган сеанслар стресс - эмоциональ характерда бара. 40ар минутка сузылган беренче өчесендә авырудан психоэмоциональ нагрузка төшерелә. Хәтерегезгә төшерегез, сезнең ирегез яки улыгыз әкәмтөкәм шикелле үз-үзенә бирелә, әйтерсең тирән йокыга тала. Һәм аны бу хәлдән арындыруы бик кыенга туры килә. Шундый чакта табиб өчен авыруның үз-үзенә ярдәмгә килүе мөһим. Эчүчелеккә ничек каршы торырга? Эчәсе килү теләген булдырмау өчен нәрсә эшләргә? Ничек итеп яшәү рәвешеңне үзгәртергә, ачу, гаебеңне танымаудан котылырга? Пациентның менә шундый һәм башка бик күп сорауларына җавап бирәчәк табиб. Әлбәттә, индивидуаль тәртиптә. Ә дүртенче, унынчы сеансларда? Аларның максаты-авыруларда алкогольгә карата җирәнү хисе тудыру. Сеанслар бер сәгать, сәгать ярым дәвам итәргә мөмкин, һәм анда табибка бөтен көчен куярга туры килә: шәхси ихтыярыңны да эшкә җикмичә тембр, пауза яки интонацияне көчәйтеп текстны укып чыгу гына бернинди нәтиҗә бирмәячәк. Хәер, белгечләр раславынча дәвалауның нәтиҗәлелеге күп вакыт табиб белән пациент элемтәсе, авыруның теләге дәрәҗәсенә бәйле.

Гипноз бөтен дәваны да коткармый, бу хакта укучыга да яхшы мәгълүм. Наркология бүлегендә дәвалауның башка ысуллары да кулланыла, әйтик, кодлаштыру, «торпедо» препаратын кертү. Дәвалану курсы үткәннән соң бер сәгать буена авыру табиб күзәтүе астында була, һәер, кызганычка каршы, аена бер тапкыр наркологка килергә дигән таләп һәрвакыт үтәлми. Борынгы тибет медицинасы кануннары буенча, организм тулысынча бер елда гына үз көчен ала. Менә авыру П. тугыз ай эчми. Табибка килергә ашыкмый, терелдем, дип уйлый. Ләкин...яңадан эчә башлый. Хатыны «ярдәм итә». Өйгә туганнар килгәч аның алдына рюмканы үзе куя, туганнар үпкәләмәсен, янәсе. Менә шундыйлар һәм башкалар өчен наркология бүлеге АКШ тагы аноним алкоголикларның гаилә группалары штаб - квартирасыннан махсус әдәбият кайтарта. Менә шуларның берсе болай башлана: «Алкоголизм-гомер буена бара торган чир. Аны туктатуның бердәнбер юлы - тулысынча тыелу».

**Т.НАЗАРОВА.**

# Ювелир Петров

**Сирәк һөнәр кешеләре**

- Алтын чылбырым өзелде, кем артыннан Казанга ремонтка җибәрим икән?

- Балдакны кечерәйтәсе иде...

Дөнья булгач, кайчак алтын әйберләр дә өзелә, бөгелә, башка төрле ремонт таләп итә. Вак кына ремонтны да теләсә кем башкара алмый. Ярый ла, зур шәһәрләрдәге кебек адым саен ювелир цехлары булса. Ә менә безнең Норлатта яшәүчеләргә ни эшләргә тәкъдим итәрсез? Шәһәребезнең бер генә почмагында да ювелир пунктлары юк. Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсендә дә ювелир эшләми. Ә менә тимер юл аркылы һава күперчеге янында ук Спортивная урамындагы 6 нчы йортның 2 нче фатирында яшәп ятучы алтын куллы оста барлыгын шәһәрдә бик азлар белә. Фатирына терәп төзелгән кечкенә янкормада заказлар кабул итә, кайберләрен шунда ук эшләп тә бирә ул. Лицензиясе, башка төрле документлары да тәртиптә. Югыйсә, бу сирәк һөнәр кешесенә РПУның зур бүлмәләреннән урын биреп эшләтсәң дә зыян итмәс иде дә...

Леонид Александровичның Башкортстаннан күчеп кайтуына ун еллап кына әле. Моңа кадәр «Башбыттехника» каршындагы курсларны тәмамлап III разрядлы ювелир белгечлеген үзләштергән иде ул. Шуңа да Норлатта да озак эш эзләп йөрмәде: РПУга ювелир итеп алдылар. Халык рәхәтләнде: инде, ниһаять, Норлатта да үз ювелирыбыз бар. Башта «Татбыттехника» да эшләгәндә, башкарылган хезмәтенең 40 проценты күләмендә хезмәт хакы ала иде ул. Ә соңрак идарә буйсынуына күчкәч, хезмәт хакы процентлары 25кә генә калды. Балык тирәнне, кеше яхшыны эзли диләр бит. Леонид та ябыштыру, келәйләү кебек вак, әмма җаваплы булган эш өчен халыктан әллә ни зур хак, һәм, инде зур хезмәт хакы ала алмаганын аңлап, эштән китәргә булды. Шулай да, кешеләрнең тәҗел йомышы төшкәндә аның өенә килеп булса да теге яки бу эшне башкаруны үтенәчәкләрен алдан фаразлап, лицензия дә алды. Леонид Александрович ялгышмады: кеше бетеп тормый аның өеннән. Бер - берсеннән ишетеп, оста Петровны эзләп табалар. Ә Леонид Александрович кеше үтенечен аяк астына сала торганнардан түгел: вак заказларны кеше күз алдында ук башкарып бирә, катлаулыраклары өчен срок куя. Ә инде останың теге яки бу эшне срогына үтәмәгәнен һичкем хәтерләми. Башкарган эшенең сыйфаты да һичкайчан тел - теш тидерерлек түгел. Кешедән канәгатьсезлек ишетмәсен өчен үз өендә җайлаштырылган кечкенә кабинетын да үз куллары белән, бөтен нормаларга туры килерлек итеп җиһазлады ул. Балдаклар кечерәйтү һәм зурайту станоклары бар. Вак эшләр өчен төрле үлчәмдәге пинцетлары, кыргычлары, ювелир кайчылары, миллиграммнарны да үлчәрлек үлчәгечләре, пумалалары бар. Еллар үтү белән күз күрү сәләтенең кимүе сәбәпле зурайтып күрсәтә торган пыялалары да берничәгә җыелды, ә бүлмәдәге җыйнаклык, тәртип... искиткеч.

Леонид Александрович белән саубуллашканда, аның киләчәккә планнары белән дә кызыксындык.

- Ювелирлык эшен ташламамдыр инде, - диде ул. - Кеше өчен кирәкле бу һөнәр - минем ашатучым гына түгел, ә бәлки хоббием да бит. Үз өем янына иркенрәк бина төзеп, ювелир пункты ачу максатым.

Бик хуп. Шәһәр өчен бик кирәк нәрсә бу. Ә инде ювелир хезмәтенә мохтаҗ кешеләр газета аркылы Петровның адресын белеп, хезмәтеннән файдалана башласалар, без дә үз информацион бурычыбызны үтәгән булып саналыр идек.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Изге Троица яме

Узган якшәмбе көнне провославие динен тотучылар Троица бәйрәмен билгеләп үттеләр. Сәләнгештә, мәсәлән, аны күп еллар инде үзенә бер төрле итеп уздыралар. Бәйрәмгә алдан әзерләнделәр: ата - аналар шимбәсендә туганнары һәм якыннарының каберләрендә булдылар, ә якшәмбе көнне массакүләм күңел ачу оештырдылар. Аның билгеләре традицион. 3 - 4 актив авыл кешесе курчакны тасмалар һәм чәчәк атучы арыш башаклары белән бизи, хуҗаларга бәхет һәм игелек теләп Троица җырлары белән урам буйлап хоровод оештыра. Быел күңел ачуны кичке сәгатьләрдә ясадылар, чөнки һәммәсе чөгендер сирәкләүдә иде. Кыскасы, эш тыгыз вакыт булса да күңел ачарга вакыт табылды. Изге Троица шулай җыр, шаян сүзләр, күңелле такмаклар белән үтеп китте.

**Н.МИХАЙЛОВА.**

# Саннар һәм факлар

Октябрь районында 6 шифаханә учреждениесе, 5 сәламәтлек пункты, 55 ФАП һәм ФП бар.

***

Шифаханә койкалары белән тәэмин ителеш 10000 кеше исәбенә 104,5 туры килә, амбулатор - поликлиника учреждениеләре планда каралганча, сменага 850 кеше кабул итә ала.

***

1996 елда район шифаханәләре стационарларында 25 меңләп авыру үтә, амбулатор - поликлиникага 300000 тапкыр мөрәҗәгать итү булган, 18300 ашыгыч медицина ярдәме хезмәте күрсәтелгән.

***

1000 кешегә туу күрсәткечләре кимүгә бара: 1994тә - 137 процент, 95тә - 12,9, 96да - 12,1, үлем фактлары 1994 тә - 14,7, 95тә - 12,9, 96да - 14,4 процент.

***

Медицина хезмәткәрләренең район буенча уртача хезмәт хаклары - 691848 сум, табиблар - 1191000, урта медицина хезмәткәрләре - 587825, кече медицина хезмәткәрләре 296700 сум хезмәт хакы алганнар.




# «Известия»га - бары 8 кеше

Районда 1997 елның II нче яртыеллыгына газета - журналларга язылу кампаниясенең I этабы тәгәлләнде. Бу чорга барысы 728 млн. сумлык газета - журналларга язылдылар. Октябрьлеләр иң күп язылган газета - «Труд» (833 экз.), ул күп дистә еллар ныклы, ышанычлы информация чыганагы булып тора. Һәм тагы - ул хезмәт - төп яшәү чыганагы турында яза, берочтан эшләүчеләрнең мәнфәгатен дә яклый. «Крестьянка», атналык «Аргументлар һәм фактлар», «Комсомольская правда» һәм «За рулем» басмаларын да бездә үз итәләр. Ә менә «Российская газета»ны 32, ә «Известия»не 8 кеше генә алдырачак. Алдагы яртыеллыкта аны 15 кеше алдырган булган. Басма - җитди, күпкырлы газета, бер генә тере теманы да калдырмый. Тик менә бәясе генә!.. Әйе, ярты еллык газета өчен 100 менне теләсә кем чыгарып сала алмый шул. Ә менә балалар теләген күпләр үтәргә тырыша. 315 гаилә популяр «Миша» журналын, ә 204 гаилә «Веселые картинки»ны алдырачак.



# УН сорауга - җавап

***Районыбыз хуҗалыкларында кооперативлар оеша башлагач, безгә газета битләрендә аның асылы, җир, җир пае, аренда мәсьәләләре турында аңлатып язуыбызны сорап редакциягә хат юллаучылар байтак. Күпсанлы укучыларыбызның үтенечләрен канәгатьләндерү йөзеннән без җир ресурслары һәм җир реформасы буенча район комитеты рәисе Ә.М.Шәһиәхмәтовка мөрәҗәгать иттек. Түбәндә безнең сорауларга аның җавапларын урнаштырабыз.***

**- Нәрсә ул җир пае?**

- Авыл хуҗалыгы предприятиесенең милек хокукында пай алырга хокукы булган затка тиешле авыл хуҗалыгы җиренең бер өлеше ул. Авыл хуҗалыгы оешмасы карамагында булган барлык авыл хуҗалыгы җирләре җир оешмасының үз пайларын алырга хокуклы кешеләр санына бүленә. Сез бушлай алырга хокуклы җир паен билгеләгәндә нигез итеп уртача район нормасы алына. Безнең Октябрь районында ул 5,22 гектар итеп билгеләнә. Пай билгеләгәндә хезмәт кертеме һәм стаж исәпкә алынмый.

**- Җир паена кем хокуклы?**

- Җир паен түләүсез алуга түбәндәге кешеләр хокуклы:

а/ хуҗалыкта даими эшләүчеләр.

б/ хуҗалык пенсионерлары.

в/ авылдагы социаль сфера хезмәткәрләре.

г/ вакытлыча читкә киткән эшчеләр (армиядә хезмәт итүчеләр, укучылар, декретта булучылар һ.б.).

д/ җиргә хокукы булган үлгән кешенең варислары.

Район хакимияте башлыгының җирне коллективның гомуми пай милеге карамагына тапшыру турында күрсәтмә биргән көненнән җир алу исемлегенә кертелгән гражданнар җир пае алуга хокуклы.

**- Җиргә милек хокукына таныклыкны кайдан һәм ничек алып була?**

- Җирле үзидарә органнарыннан. Әгәр аны сезгә бирмәсәләр җир реформасы һәм җир ресурслары район комитетына яисә судка мөрәҗәгать итә аласыз.

**- Җир налогы турында сөйләмәссезме икән?**

- Җир паегызны арендага биреп, сезгә җир паегызны файдаланган кеше белән килешү төзү отышлырак. Шунда ук налог түләүне аның вазифасы булуын төшендерегез. Әгәр дә сез бу турыда алдан килешмәсәгез, җир пае өчен налог түләү үз өстегезгә кала.

**- Җир паен кем арендага бирә ала?**

- Җир паеның теләсә кайсы милекчесе (эшләүче һәм пенсионерларны кертеп) үз җир пайларын арендага тапшыра алалар.

## *Җир турында сөйләшәбез*

Аренда - җир пае белән эш итүнең иң нәтиҗәле юлы. Ни өчен дигәндә, бу очракта сезнең җиргә милек хокукыгыз саклана. Шул ук вакытта сез ел саен аренда түләве формасында керем дә аласыз.

**- Җир паен арендагы кемгә тапшыру мөмкин?**

- Җир паен арендага авыл хуҗалыгы производствосы белән шөгыльләнүче теләсә нинди гражданга яисә предприятиегә бирү мөмкин. Әгәр дә сез авыл хуҗалыгы ширкәтендә яисә крестьян хуҗалыгында эшләсәгез, паегызны арендага үз предприятиегезгә бирергә тиешсез. Әгәр дә инде предприятие аннан баш тартса, аны башка предприятие яисә гражданга тапшыру мөмкин. Арендатор сайлаганда, ул көткән реаль мөмкинлекләр белән кызыксыныгыз. Керем булмаса ул сезгә паегыз өчен аренда түләвен дә түли алмаска мөмкин.

**- Җир паен арендага тапшыру килешүе нинди срокка төзелә?**

- Ким дигәндә 3 елга. Әгәр дә инде килешү шартлары сезне канәгатьләндерсә, килешү автомат рәвешендә бер елга озынаая бара. Теләсә нинди моментта сез килешү шартларын үзгәртергә (арендатор белән килешеп) хокуклы. Әгәр дә инде арендатор килешү шартларын үтәмәсә, аны арендатор рөхсәте белән яисә суд тәртибендә өзәргә мөмкин.

**- Җир паен арендалау килешүенең төп шартлары нидән гыйбарәт?**

- Килешү төзегәндә түләү шартларына аерым игътибар бирергә кирәк. Килешү җир пае өчен ел саен аренда түләве өчен исәп - хисап ясауны күздә тота. Әгәр дә аренда түләвенең күләме нинди булуы турында икеләнсәгез, хуҗалык белгечләренә мөрәҗәгать итегез.

Аренда түлевенең күләме билгеләнгәч аны тулаем шартларын билгеләргә кирәк. Аренда түләвен акчалата, продукция белән, хезмәт күрсәтү исәбенә түләргә мөмкин.

**Аренда түләвенең продукциялата түләүне таләп итү урынлымы?**

- Урынлы. Әгәр дә түләү продукциялата икән, продукция төрләре, саны һәм түләү вакыты билгеләнергә мөмкин.

Үз производстволарында җитештерелгән продукция белән аренда түләгәндә, ул 50 минималь окладтан артмаганда налог алынмый.

**- Түләү хезмәт күрсәтү белән булганда...**

- Аренда түләве исәбенә хезмәт күрсәтүгә бакча сөрү, утын китерү һәм башкалар керә.

**Сорауларны Р.ГИНЯЕВА бирде.**

***Редакциядән: Җир, җир паена кагылышлы бу сөйләшүне без алга таба да дәвам иттерергә уйлыйбыз. Бу уңайдан сорауларыгыз, тәкъдим, фикерләрегез булса, язып җибәрегез, хөрмәтле газета укучыларыбыз.***

## *Урак якынлаша*

# «Быел да сынатмабыз»

Салдакайда. узган ел урак өстендә булырга туры килгән иде. Басудагы күтәренке хезмәт ритмына сокланып кайттык без: алны - ялны белми эшлиләр иде комбайнчылар. Тырышлыкның нәтиҗәсе дә озак көттермәде: «Родина» уракны беренчеләрдән булып төгәлләде, кырларның уңдырышлылыгы да югары булды.

- Быел да сынатырга исәп юк,- диде безгә хуҗалыкның баш инженеры Олег Николаевич Миронов һәм уракка хәзерлекнең барышы турында сөйләп китте. Аннан аңлашылганча, хуҗалык бу мөһим кампанияне һәрьяклы хәзерлек белән каршы ала. Әнә, 9 комбайнның барысы да диярлек әзер бүген. «Нива»лар иске инде. Шулай булса да хуҗалыкның инженерия хезмәткәрләре аларга өчен кирәкле запас частьләрне юнәтү - табыштыру өчен бар көчләрен куйганнар. Әле куәтле «ДОН»нары да бар. Ул бер генә данә булса да, елның - елында байтак мәйданда эш башкара. Билгеле инде ватылып - нитеп тормаса. Әмма инженерия хезмәткәрләре ышандыруынча, «ДОН» быел да көйле эшләячәк, чөнки җирле осталар көче белән төзәтелгән ул. Үземә дигәндә, кемнең начар эшлисе килсен икән ул. «Сельхозтехника» осталары өчен генә бит ул «миннән киткәнче, иясенә җиткәнче...». Шулай бер елны берләшмәдә төзәттергәннәр иде комбайннарын, җәй буе шулар белән иза чиктеләр. Ә быел, ходайга шөкер, вак - төяк җитешсезлекне искә алмаганда барысы да диярлек әзер.

Уракта катнашачак автомашиналар да аерым исәптә быел. Машина - трактор паркындагы 20ләп автомашинаның бишесе генә эшләячәк уракта. Аларның йөк күтәрүчәнлеге, файдалану срогы, төзеклеге һәм, билгеле инде, шоферның осталыгы - барысы да исәпкә алынган. Әрҗәләрен бөртек коелмаслык итеп герметиклаштыру бурычы да җиткерелгән шоферларга.

Хуҗалык администрациясе урак чорында басуда, ындыр табакларында эшләячәк кешеләрне дә күпкә алдан барлап, билгеләп чыгарга ниятли. Хуҗалыкта исә хуҗасыз комбайннар юк. Элеккеге еллардагы кебек үк Николай Ефимов, Николай Кириллов, Анатолий Кольцов һәм башкалар утырачаклар кыр кораблары штурваллары артына. Ә алар иген кырында бер тапкыр гына сыналган егетләр түгел. Икмәк язмышы хәл ителгәндә ял белән санашмыйча, җир җимертеп эшли торган игенчеләр алар.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Олы хезмәт юлы алда әле



Сергейның олы хезмәт юлы әле алда. Аласы тәҗрибәсе, аралашасы кешеләре, үзен төрле яклап күрсәтәсе, төрле үрләр яулыйсы да алда. Ләкин яшьтән үк тырыш, булган кешенең киләчәктә уңышка ирешәсе гаҗәп түгел. Тикмәгә генә «Тырышкан табар, ташка кадак кагар», димиләр бит. Нәкъ шул сыйфатны ходай Сергейга да биргән. Әле күптән түгел генә хуҗалыкта токарь булып эшли башлаган иде, коллективта тырышлыгын, булдыклылыгын күрсәтергә өлгерде.

**Рәсемдә: «Заветы Ильича» КХАсы токаре С.Крестин.**

## *Илдә ниләр бар?*



### Иркле бәяләр

Сөт, он тарттыру, икмәк пешерү промышленносте эшен тотрыклыландыру, җитештерелә торган продукциянең ассортиментын арттыру, халыкның ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 4 июньдәге 466 нчы карары белән икмәккә, икмәк - булка әйберләренә, онга, манный ярмасына, сөт һәм сөт продуктларына иректе бәяләр кертелә. Бу эш өч ай дәвамында башкарылачак. Бу чорда әлеге продукцияне күпләп сату - җибәрү бәяләре Куллану-чылар хокукларын яклау комитеты белән килештерелергә тиеш. Моннан тыш сәүдә өстәмәләре чикләнелә (мәсәлән, икмәккә күп дигәндә 15 процент).

### Рудольф Нуриев мирасын бүлешә алмыйлар

Рудольф Нуриевның Америка ягындагы мирасы хакында АКШта шау - шу купкан. Танылган биючеләнең туганнары «Рудольф Нуриев исемендәге бию фонды»на 7 миллион доллар күчерергә риза түгелләр. Алар уйлавынча, танылган мастер бервакытта да андый фонд төзергә уйламаган. Аны андый васыять төзергә бик каты авырган вакытында адвокат Бэрри Уэнстон мәҗбүр иткән. Нью - Йорк федераль судына бирелгән дәгъвада әлеге адвокатның бу фондта президент булуы һәм хатыны белән кызын, зур хезмәт хакы билгеләп, эшкә алганлыгы турында язылган.

### Утыгызны сүндереп йөрегез

Әйе, бар иде ул электрның киловатт - сәгате өчен 4 тиен түләгән чаклар - сагынып сөйләргә генә калды. Күңелегезгә авыр алмагыз: шулай да Федераль энергетика комиссиясе (ФЭК) 1 июльдән электр энергиясенә бәяләрне бермә - бер арттырырга җыена. Ягулык һәм энергетика министрлыгының беренче урынбасары Виктор Кудрявыйның әйтүенә караганда, аларның бу ниятен хөкүмәт якларга тиеш.

Быелның беренче кварталында һәр киловатт - сәгать электр энергиясенең үзкыйммәте 207 сум булган. Промышленность аны 238 сум итеп түләгән, ә без нибары 81 сумын, ягъни өчтән берен генә түләгәнбез. Мәскәүдә бүген үк инде 130 - 180 сум түлиләр. Димәк тиздән бездә дә шулай булачак. Һәр гаилә электр энергиясе өчен генә ай саен уртача 20 - 40 меңен чыгарып салырга тиеш булачак.

# УЛ КӨН ТАУ АРТЫНДА ТҮГЕЛ

***Билгеле булганча, яңа ягулык сезонында шәхси йортларда яшәүче хуҗалар җылылык энергиясе өчен хәзергеннән 22 тапкырга артыграк түләячәкләр. Юк, бу Норлат җылылык челтәре предприятиеләренең икътисадый иреклеге түгел, ә ТРсы МКның 1013 нче (1996 елның 30 ноябре) һәм 104 нче (1997 елның 4 феврале) карары буенча гамәлгә ашырыла. Инде тагын да төгәлрәк булыйк дисәк, яңа тарифлар февральдән үк тормышка ашырга тиеш иде, әмма җылылык челтәрендә ситуацияне аңлап, бу яңалыкка килергә ашыкмадылар. Менә бу хакта җылылык челтәрләре предприятиесе экономисты ВЕРА ЕВГЕНЬЕВНА ВЫРДИНА нәрсә сөйли.***

- Ягу сезоны 1 октябрьдән декабрьгәчә һәм гыйнвардан 9 майга кадәр сузыла. Барлыгы 7 ай. Безнең кулланучыларыбыз бу хезмәткә ике тапкыр түли иделәр, хәзер ай саен түләргә туры килер, мөгаен. Элеккеге бәя 1 Гкал.гә 2105 сум өч ел дәвамында гамәлдә иде. Килешегез, бу күп түгел. Ләкин энергия - ягулык ресурсларына бәяләр даими рәвештә үсеп тора бит... Дөрес, бу бик зур сикереш, халыктан акча җыюы да кыенга туры киләчәк. Бәлки менә бу язма да булышыр.

Җылылык энергиясенә түләү йортның күләменнән чыгып бәяләнә. Димәк, йорт никадәр зуррак булса, шулкадәр күбрәк Гкал файдалануга китә. Шунда ук экономист саннарда күрсәтү өчен берничә хисаплау да ясады. К. гаиләсе усадьба тибындагы йортның яртысын били. Йортның күләме 800 куб.м., ул 75,8 Гкал.гә тигез, аларның һәркайсына хуҗасы 47300 сум акча түләргә тиеш. Шулай итеп 160 мең сум автоматик рәвештә 3 млн. 600 мең сумга күтәреләчәк. Аз түгел, шулай бит?

Мария Петровна Т. льготадан файдаланучылар рәтенә керә һәм коммуналь хезмәтләр өчен 50 процент кына түли. Йорты иске, хәзерге заман үлчәмнәре белән бик кечкенә - 94 куб м. (12,44 Гкал). Ул елына 13 мең сум түләгән. Хәзер аңа 295 мең сумын чыгарырга туры киләчәк. Бу аның пенсиясеннән аз гына күбрәк. Мария Петровна бу яңалыкны ныклык белән кичерә: «Өлешләп түләрмен...»- ди. Шунысын әйтергә кирәк, нәкъ пенсионерлар взносларны үз вакытында, соңармыйча түләп баралар икән. Апрельдән аларга нәкъ шул, коммуналь хезмәтләр өчен түләү максаты белән жетоннар тапшырдылар. Бу да ярдәм булыр, бәлки.

Башка җылылык энергиясе кулланучыларга үз мөмкинлекләреннән исәпләргә туры киләчәк - ягу сезоны дүрт айдан башлана.

**Т.НАЗАРОВА.**

***Спорт • Спорт • Спорт***

## «Яшүсмерләрнең файдасы тиде»

**<u>Район мәгариф бүлеге каршында эшләп килүче «Яшүсмер» профиль лагеренең беренче агымын футболныкы дип атап булыр иде, мөгаен: лагерьда ял иткән 90 баланың 60сы футбол сөючеләр иде. Балалар ялының ничек оештырылуы, аның нәтиҗәлелеге турында сөйләвен үтенеп, без бу агым өчен җаваплы кешеләрнең берсе - ДЮСШ директоры А.В.ХАРДИНГА мөрәҗәгать иттек. Ул безгә менәниләр сөйләде:</u>**

- Ял бик кызыклы үтте. Балалар ярдәмче интернат - мәктәптә яшәделәр. Алар көнгә 4 тапкыр ашатылды. Яшүсмерләр өчен төрле чаралар үткәрелде. Ял итүчеләр экскурсияләргә дә йөрделәр.

Балаларның яллары исә аеруча нәтиҗәле булды. Бер генә көн дә спорт тренировкаларыннан башка узмады. Төп максат - республика зона ярышларына хәзерләнүдән гыйбарәт иде. Көндәлек тырышлык якын арада ук үзенең нәтиҗәләрен дә күрсәтте. Һәрхәлдә агым азагында башланган республика ярышлары да ачык күрсәтте моны. Мисал өчен, 1986 - 1987 нче елларда туган яшүсмерләр арасындагы футбол ярышлары Норлатта үтте. Бирегә Әлмәт, Түбән Кама, Бөгелмә кебек зур шәһәрләрдән командалар килде. Күрше - тирә районнар футболчылары да бар иде араларында. Ярышта беренчелекне Норлат командасы яулады. Дүртенче мәктәптән Дима Киселев (тренеры В.П.Трофимов) иң яхшы уенчы итеп танылды. Бөгелмәлеләр икенче урынга калды, Түбән Кама футболчылары исә өченче урынга чыктылар.

Шул ук срокта Алабуга шәһәрендә дә ярышлар үтте. Анда 1984 - 1985 нче елда туган яшүсмерләр көч сынашты. Шунысы куанычлы, сигез команда арасында норлатлылар дүртенче нәтиҗә күрсәттеләр.

1982 - 1983 нче елларда туучылар арасында Менделеевскида үткән ярышларда катнашып та дүртенче урынга чыктылар октябрьлеләр.

Менә шундый нәтиҗәләр. Хәзер 1986 - 1987 нче елларда туган һәм Норлатта үткән ярышларда беренчелекне бирмәгән егетләребез июль азагында Чистай шәһәрендә үтәчәк финал уенында катнашырга әзерләнәләр.



## «Күн туп» призына

Футбол буенча «Күн туп» призына үткән район зона ярышлары зур оешканлык белән узды.

Анда яшүсмерләр дүрт яшь группасы (1980 - 1981; 1982 - 1983; 1984 - 1985; 1986 - 1987) буенча көч сынаштылар. Шәһәр мәктәпләре берьюлы ике стадионда ике түгәрәктә уйнадылар. Соңрак районның авыл мәктәпләре катнашында финал ярышлары үткәрелде. 1986 - 1987 нче елларда туучылар арасында беренчелекне дүртенче мәктәп командасы яуласа, беренче һәм Егоркино урта мәктәпләре икенче һәм өченче урыннарга чыктылар.

Калган өч яшь группалары арасында өч тапкыр беренчелекне өченче мәктәп командасы яулады. Егоркино урта мәктәбе футболчылары ике, Якушкино өч, беренче мәктәп командасы бер тапкыр призлы урыннарга чыкты. Җиңүче командаларның һәркайсы Мактау кәгазьләре һәм кыйммәтле призлар белән бүләкләнделәр. Дүртенче мәктәптән Дима Киселев, беренчедән Дима Воскобойник һәм өченче урта мәктәптән Женя Фомичев иң яхшы уенчылар итеп танылдылар.

**А.ХАРДИН.**

## 01 хәбәр итә

## Куркыныч чыбыр

ТРның янгын күзәтчелеге янгыннар нәтиҗәсендә кешеләр үлеме күзәтелүен борчылып хәбәр итә. Мондый янгыннар статистикасы куркыныч: 1997 нче елның 1нче маена республика күләмендә 1300 янгын очрагы теркәлгән, аның күп өлеше торак секторга туры килә. Янгында 86 кеше һәлак булган, аның 7 се - 16 яшькәчә балалар.

Кешеләр үлеменә китергән бу фаҗигаләрнең сәбәбен анализлау шуны күрсәтә: 77 янгын торак йортларда булган, ягъни 10 очракның 9сында кеше үз йортында һәлак булган. 23 кеше тормышы белән йоклаган хәлдә хушлашкан, 31 кеше 60 яшьтән узган булган. Мондый фаҗигале янгыннарның сәбәбенә кагылып, Дәүләт янгын күзәтчелеге 174 янгын очрагының исерек кешеләр гебе белән килеп чыгуын билгели. Кешеләр әлегәчә «кәеф - сафа - аракы - сигарет» чылбырының янгынга китерүен аңлап җиткермиләр. Өстәвенә, статистика күрсәтүенчә янгын сәбәпчеләре аның корбаны да булып куялар.

Әчкечелек, төзексез электр үткәргечләр, ут белән саксыз эш итү - торак йортлардагы янгынның төп сәбәпчеләре болар. Әмма «кызыл әтәч»не булдырмау өчен бары янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә кирәклеген әле дә оныталар. Эссе көннәр башлану белән урман массивларында янгын очраклары ешайды. Шуңа да ут белән сак булыгыз.

**Октябрь янгын частенең Дәүләт янгын күзәтчелеге.**



## Белдерүләр

### Сатабыз

**1996 елгы ВАЗ - 21065.** Тел.: 5 - 25 - 72.

***

**ВАЗ - 2101, кыйммәт түгел**. Тел.: 5 - 22 - 58.

***

**ВАЗ - 21099, гранат төсендә, әйбәт хәлдә.** Тел.: 5 - 26 - 86.

***

**6 х 10 метрлы йорт, 30 сутый бакчасы, 10 х 3 метрлы верандасы бар. Чулпан авылында Мөхәммәтшинга мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 3 - 82 - 73.

***

### Алмаштырабыз

**Шәхси йорт 2 яки 1 бүлмәле фатирга алыштырыла**. Тукай ур., 23 йортка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Ашыгыч рәвештә бер бүлмәле хосусыйлаштырылган фатир (гомуми мәйданы 30 кв. метр) һәм 1984 нче елгы яхшы хәлдәге «Жигули» ике бүлмәле фатирга**. Тел.: 5 - 20 - 03.

***

### Төрлесеннән

**16 июньгә каршы төндә 5 яшьлек кара төстәге овчарка югалды.** Күрүчеләрнең бүләк бәрабәренә түбәндәге адрес буенча хәбәр итүләрен сорыйбыз: Горький ур., 12., тел.: 5 - 29 - 17.

***

**<u>Галиуллина Лилия Шәрифҗановна исеменә 2 нче мәктәп тарафыннан бирелгән А 695414 таныклыкны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.</u>**

***

**<u>Алабуга 79 нче Пл тарафыннан Гайфуллин Зөлфәт Әсгатович исеменә бирелгән 291933 номерлы дипломны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.</u>**

***

**<u>Ларкин Виктор Федотович исеменә документлар табучыны Гыйматдинов ур., 107 - 1 адресы буенча иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз (бүләк бәрабәренә).</u>**

***

**Физик һәм юридик затлардан «Россия саклык Банкы»ның өстенлекле һәм гади акцияләрен сатып алабыз**. Тел75 5 - 29 - 95.

***

<u>Шәхси йортларда яшәүче шәһәрлеләр игътибарына! Элек судан, канализациядән һәм МПП контейнерларыннан файдаланган өчен акча түләмәүчеләрнең бу хезмәтләр өчен түләүгә килешү төзү өчен МПП конторасына килүләрен сорыйбы</u>з. Адрес: Гагарин ур., 13а. Түләү 1997 нче елның гыйнварыннан алына.

**ЖКХ МППсы администрациясе.**

***

***Саклык банкы счетында акчалары булган кешеләрнең теләге буенча әлеге средстволар валюта алуга һәм моннан ары кертемне АКШ доллоры исәбендә алып баруга юнәлтелә ала.*** Саклык банкына (К.Маркс ур., 51 мөрәҗәгать итәргә.

### Очрашуга чакырабыз

***Колбай Мораса урта мәктәбен 1972 нче елда тәмамлаучыларның очрашуы 28 июньдә 10 сәгатьтә булачак.***





***1982 нче елда Киекле урта мәктәбенең 10 нчы Б классын тәмамлаучыларның очрашуы 28 нче июнь көнне 13 сәгатьтә булачак.***

Татарстан Республикасының Октябрь районы страхование ачык типтагы акционерлык җәмгыяте әтисе үлү сәбәпле, баш бухгалтер Суфия Нургали кызы Вафинаның тирән кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасының Октябрь районы страхование ачык типтагы акционерлык җәмгыяте әнисе үлү сәбәпле, агент Фәүзия Сәлих кызы Кыямованың тирән кайгысын уртаклаша.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7200